# Мастер класс
# по географии

# География дәресләрендә тәнкыйди фикерләү технологиясе ысулларын куллану

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының**
**«Качкын төп гомуми белем бирү мәктәбе»**
**муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе**



Гибадуллина Рәзилә Наил кызы, беренче квалификацион категорияле география-биология укытучысы

Методик темам:

* Укучыларның танып- белү эшчәнлеген һәм мөстәкыйль-леген үстерү

# Максатлар:

**Икенче буын стандартлары** шәхес үсешен тәэмин итү, укытуга үз эшеңне төптән белеп якын килү бурычын куя. Башкача әйткәндә, мәгариф системасы баланы белемле итү хакында гына түгел, аңа күнекмәләр бирү, аны эшкә өйрәтү турында да кайгырта

Димәк ,мастер классымның **максаты:** Укытучыларның һөнәри үсешенә шартлар булдыру; география дәресләрендә тәнкыйди фикерләү технологияләрен куллану алымнары белән таныштыру, әлеге алымнарны практик кулланырга өйрәтү.

укучыларның **интеллектуаль** фикерләү сәләтләрен үстерү;
**танып-белү эшчәнлеген** үстерүгә юнәлтелгән күнекмәләр булдыру.

# Бурычлары:

**1. Укучы һәм укытучы арасында иҗади хезмәттәшлек булдыру;**

**2.Укучыны креатив эшчәнлеккә тарту;**

**3.Белем бирү процессын оптимальләштерү,**

**4.белем алуга уңай омтылыш (мотивация) булдыру.**

* **ТФТ- укытучы эшчәнлеге**

Укучының эшенә дөрес юнәлеш бирә;

* Мөстәкыйль фикер йөртүгә этәргеч ясаучы шартлар булдыра;
* Төрле фикерләрне каршы куя;
* Нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә;
* Гомумиләштерә,бәяли.

**Укучы эшчәнлеге**

- Проблеманы чишә;
- Дәлилләр эзли;
- Башкаларның фикерен тыңлый;
- Уйлап эш йөртә;
- Бәя бирә.


# Тәнкыйди фикерләү технологиясенә корылган дәрес өч этаптан тора:

- *өйрәнелә торган темага кызыксыну уяту*
- *төшенү (аңлау)*
- *рефлексия.*


Кызыксыну уяту һәр дәрестә була. Бу өйрәнелә торган тема яки проблема буенча укучының элекке белемнәрен актуальләштерү һәм гомумиләштерү һәм актив эшчәнлеккә ныклы кызыксыну уяту өчен кирәк.

Төшенү (аңлау) этабында укучы өйрәнелә торган материал буенча яңа мәгълүмат ала, төшенчәләрне, фактларны аңлап, элегрәк алган белемнәрен яңалары белән бәйли, тулыландыра.

Рефлексия этабында укучы өйрәнгәннәрне бербөтен итеп күзаллый, яңа мәгълүматны тулысынча үзләштерә, иҗади фикер йөртә һәм өйрәнелә торган материалга карата аның шәхси мөнәсәбәте формалаша.


кәрзин
инсерт
синкв
ейн
кластер
ысуллары
фишб
оун,
паузалар
ясап уку.
дидакт
ик уен
терәк
конспе
кт

# Рәсемнән 10 кешене табарга





* **МИСАЛНЫ Ң ГАМӘЛЛӘРЕН ДӨРЕС ЧИШУ НӘТИҖӘСЕНДӘ ТИЕШЛЕ ГЕОГРАФИК ОБЪЕКТ КИЛЕП ЧЫГАР:**

**(11,21- (38,418:0,3 – 4,8 *11,6) :11 + 13,79 =**

**72,38 - й 18,42 – л**

**18,42 – л 128,06 - б**

**4,63 - а 6,58 - к**

**55,68 – а**

# «Кластер төзү» ысулы

**Кластер тексттагы фикерләрне, төшенчәләрне аерып алу һәм аларның мәгънәви бәйләнешен график сурәттә күрсәтү дигән сүзне аңлата**

# «Кластер төзү» ысулы



# Синквейн төзү

* Байкал
* Чиста,тектоник
* Туена,яшәтә, туендыра
* Төче сулы иң тирән күл.
* Сулык-Күл






НУРЛАР


РОССИЯ

# ЙОМГАКЛАУ

Алым һәм методлар төрлелеге максатка ирешү чарасы булып тора. Кемнеңдер эш системасын яки ул куллана торган технологияне алу кыен, һәр педагог үзенең мөмкинлегенә, иҗади карашларына, укучыларның ихтыяҗына карап, үз эш алымнарын булдырырга тиеш. Иң мөһиме — белем сыйфаты, эшнең нәтиҗәлелеге.Яңа технологияләр куллану укуга кызыксыну уята, иҗади эзләнүне активлаштыра, фикерләү сәләтен үстерә. Иң мөһиме - укытучы үзенең эш нәтиҗәсен укучыларының уңышлары аша күрә. Шул очракта гына укучының фән белән кызыксынуы арта, ул дәрестә алган белемне төрле ситуацияләрдә кулланырга өйрәнә, кыскасы, иҗади фикерләүче шәхес формалаша.

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!